**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Күләгәш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**10 ноября 2025 года** **№ 1**

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 10 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта "Әгерҗе муниципаль районының « Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекләләр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан ( ата-аналар, ирләре яки хатыннары), I төркем инвалидлардан , өлкән яшьтәге ялгыз гражданнардан (80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәкләрдән), көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчасын 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне:

1) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарын һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; насос сатып алу һәм хезмәт килешүе буенча түләү; Күләгәш торак пунктын су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

2) Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт килешүе буенча янгын сүндерү машинасын йөртүчегә түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

3)Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, фонарьлар сатып алу һәм алыштыру; хезмәт килешүе буенча түләү; урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

4) Күләгәш торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Совет урамындагы, Спорт тыкрыгындагы юлга салу өчен таш сатып алу һәм җәю, автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

5) Торак пункт территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрен чабу, куаклык ларны кисү, спорт тренажерлары сатып алу һәм кую, тракторны тоту һәм хезмәт күрсәтү, бензопычкы сатып алу; юлларны кардан чистарту, хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);

башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?” дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«РИЗА» «КАРШЫ»

Беркетмә нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 208 катнашучы кертелде. Гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 110 кеше, бу 53 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 110 катнашучысы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды :

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Әгерҗе муниципаль районы «Күләгәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күләгәш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан ( ата-аналары, ире яки хатыны), I төркем инвалидлардан, өлкән яшьтәге ялгыз гражданнардан (80 яшькә җиткәннәр), көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш) 2026 елда үзара салым акчаларын 500 сум күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

1) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарын һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; насос сатып алу һәм хезмәт килешүе буенча түләү; Күләгәш торак пунктын су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар;

2) Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (ягулык-майлау материаллары, янгын сүндерү машинасы өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт килешүе буенча янгын сүндерү машинасын йөртүчегә түләү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

3)Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (лампалар, фонарьлар сатып алу һәм алыштыру; хезмәт килешүе буенча түләү; урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);
4) Күләгәш торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Совет урамындагы, Спорт тыкрыгындагы юлга салу өчен таш сатып алу һәм җәю, автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар);

5) Торак пункт территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрен чабу, куаклык ларны кисү, спорт тренажерлары сатып алу һәм кую, тракторны тоту һәм хезмәт күрсәтү, бензопычкы сатып алу; юлларны кардан чистарту, хезмәт килешүе буенча түләү һәм торак пункт территориясен төзекләндерү буенча башка чыгымнар);
4.Карарны Күләгәш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтында урнаштыру юлы белән һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru). халыкка җиткерергә (https://agryz.tatarstan.ru),

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Авыл җирлеге башлыгы В.А.НИКОЛАЕВ

Совет Кулегашского сельского поселения
Күләгәш авыл җирлеге Советы
ИНН 1601002639